**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында**

Аерым затларның башка эшкә күчүе белән бәйле рәвештә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе турында» 2014 елның 25 февралендәге ПУ-217 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2014 елның 22 ноябрендәге ПУ-1065 номерлы, 2015 елның 30 июлендәге ПУ-688 номерлы, 2017 елның 20 мартындагы ПУ-231 номерлы, 2017 елның 3 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2017 елның 14 октябрендәге ПУ-911 номерлы һәм 2019 елның 2 февралендәге ПУ-58 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасында халыкның тормыш дәрәҗәсен күтәрү, хезмәт, чит ил хезмәткәрләрен җәлеп итү һәм файдалану мәсьәләләре буенча республика ведомствоара комиссиясе (алга таба – Комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Комиссия составыннан Е.А. Бабичны, Д.В. Волковны, Р.В. Гыйльмановны, М.Н. Зариповны, О.В. Земсковны, Э.Р. Лабашованы, К.Г. Садриевны, Р.З. Тимерҗановны, Д.Г. Хәмитовны чыгарырга;

б) Комиссия составына кертергә:

Анфимова Алла Леонидовнаны – Татарстан Республикасы финанс министры урынбасарын;

Демидов Виктор Николаевичны – Татарстан Республикасы буенча баш федераль инспекторны (килешү буенча);

Закиров Әнвәр Фәрит улын – Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны (килешү буенча);

Костин Артем Петровичны – Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Мәсәллимов Ильяс Габделхак улын – Россия Федерациясе Тикшерү комитетының Татарстан Республикасы буенча тикшерү идарәсе җитәкчесе урынбасарын (килешү буенча);

Мәхмүтов Марсель Азат улын – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасарын;

Сабурская Алина Викторовнаны – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Социаль үсеш идарәсенең дәүләт гарантияләре, социаль ярдәм, хезмәте һәм халыкны эш белән тәэмин итү бүлеге башлыгын;

Урманов Даян Ренат улын – Татарстан Республикасы Премьер-министрының беренче урынбасары ярдәмчесен;

Фәйзрахманов Рушан Васил улын – Россия Федерациясе Федераль куркынычсызлык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе бүлек башлыгын (килешү буенча);

Шәфигуллин Лотфулла Нурислам улын – Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Икътисад, инвестицияләр һәм эшкуарлык комитеты рәисен (килешү буенча).

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ • АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Татарстан Республикасы**
**Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 05 июнь
№ ПУ-339